| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ<br>КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-104/тэ

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-91/тэ карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2019 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2019-2020 елларга көйләнүче оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларга 2019-2020 еллар өчен үзгәрешләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 № 5-91/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-91/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018№ 5-104/тэ карары редакциясендә)

«Интергграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2016-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 574,15 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 590,15 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 528,47 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 530,26 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 530,26 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 539,99 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге